# Нәсыйхәт

җомга
22
июль 2011
№ 6

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**


# БӘЙРӘМ БЕЛӘН!

## Көтеп алынган кунак!




Безне һидәяткә күндергән, куңелләребезгә иман нурын иң зиннәтле нәрсә итеп урнаштырган Аллаһы Тәгаләгә барча мактауларыбыз булсын. Пәйгамбәребезгә рәхмәт-салаватларыбыз, сахабаларына, аңа изгелектә иярүчеләргә догаларыбыз барып ирешсен.

Белгәнебезчә, һәр әйбернең үз солтаны бар. Рамазан аен да калган 11айның солтаны дисәк тә ялгыш булмас, чөнки шушы айда Коръән иңдерелгән һәм дә Хәзрәти Мөхәммәд галәйһиссәлам шушы айда пәйгамбәр булган. Ураза гыйбадәте 624 нче елда, шәгъбан аеның 10 нчы көнендә фарыз кылынган. Аллаһ Тәгалә Коръән Кәримдә әйтә: Рамазан ае бик шәриф ай, ул айда Аллаһудан кешеләргә туры юлны күрсәтүче һәм һидәятне ачык бәян кыйлучы Коръән иңдерелде. Сезләрдән рамазан аена ирешкән һәрберегез, әлбәттә, ураза тотсын! Аллаһ сезгә җиңеллекне тели, авырлыкны теләми һәм рамазан уразасын тутырып тотуыгызны һәм Аллаһ сезне туры юлга күндергәне өчен Аны зурлавыгызны тели, шаять Аллаһуга шөкер итәрсез! (Бәкарә - 185) Шушы мөбарәк рамазан аена Кадер кичәсе яшерелгән. Аллаһ Тәгалә Үзенең китабында әйтә: Тәхкыйк Без Коръәнне кадер кичендә иңдердек. Сиңа кадер киченең шәрәфәтен вә аның хикмәтен нәрсә белдерде? Кадер киче, мең айдан да хәерлерәк сәвабы, мең ай кылган гыйбадәттән артыграктыр (Кадер 1-4)

Ураза Исламга хәтле килгән өммәтләрдә дә булган. Аларда ураза тотканнар. Бу исә ураза тотуның олы дәрәҗәле бер гыйбәдәт икәнен күрсәтә. Моңа дәлил булып Бәкара сурәсенең 183 нче аяте тора: Әй сез, мөэминнәр! Сездән алдагы халыкларга ураза фарыз ителгән шикелле, сезгә дә тәкъваллыкка ирешү өчен ураза фарыз ителде”. (Бәкара – 183).

**Дәвамы 2нче биттә.**

## Яңалыклар

**ШӘКЕРТЛӘР ТУПЛАУ БАРА**

Мамадыш мәдрәсәсе җитәкчелеге халыкның белем дәрәҗәсен күтәрү өчен зур көч куя: мәдрәсә вәкилләре тарафыннан район авыллары, мәктәпләре буенча таныштыру-чакыру эшләре алып барыла.

Бу эшнең нияте иң элек укып чыккан мөселманнарның Аллаһка табынып яшәүләре, белемнәрен башкаларга да тарату, районыбызда белемле, тиешле дәрәҗәле имамнар, Ислам нигезләренә өйрәтүче укытучылар һәм башка дин белгечләрен булдыру. Шуңа күрә яңа уку елына күбрәк яшьләрне җыю күздә тотыла.

**ЯҢА УКУ ЕЛЫНА ӘЗЕРЛЕК**

Мәдрәсә бинасында яңа уку елына әзерлек бара. Уку җиһазлары ремонтлана, буяу һәм чистарту, уку бүлмәләрен төзекләндерү эшләре алып барыла. Авырлыкларга карамыйча, бу эшләрне мәдрәсә үз көче белән башкара.

**МӘДРӘСӘ - УКУ ЙОРТЫ ДА, ДИНИ ҮЗӘК ТӘ**

Мамадыш мәдрәсәсе уку йорты вазыйфасын гына алып бару белән чикләнми, бәлки дини үзәккә әверелә бара. Мәдрәсә базасында күп санлы дини чаралар үтә: биредә авыл имамнары җыелышлары уздырыла, җәйге балалар җәйләүләре киң колач җәеп үткәрелеп килә, төрле мәҗлесләр, бәйрәм тантаналары оештырыла. Чираттагы мәдрәсәдә узачак зур чара булып мөселманнар җыенын атарга була. Җыенда төрле дини мәсьәләләр кузгалтылачак, вәгазьләр һәм нәтиҗәле фикер алышулар булыр дип көтелә.

**ЭШЛЕКЛЕ СӘФӘР**

Мамадыш мәдрәсәсе җитәкчесе Габдрахман хәзрәт эшлекле сәфәр белән Дегетле колониясендә булып кайтты. Ул анда махсус комиссия утырышында катнашты. Киләчәктә мәдрәсә белән колониянең файдалы элемтәләре, биредә рухи тәрбия чараларының зарур булуы турында сүз алып барылды.

**КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕ ЭШЛИ**

Мәдрәсәгә укырга керергә теләүчеләр өчен кабул итү комиссиясе эшли. Биредә уку-укытуга кагылган сорауларга җавап бирәләр, документларны, белешмәләрне кабул итәләр.

Белешмәләр өчен телефон: 89172802391, 89093148644

**ВӘКИЛЛӘРЕБЕЗ ҖЫЕНДА КАТНАШТЫ**

Мәдрәсә җитәкчесе Габдрахман хәзрәт район мөхтәсибе Илһам хәзрәт белән берлектә Урта Сон авылында үткәрелгән мөселман җыенында катнашты. Биредә Рамазан аена багышланган мәсьәләләр хакында сүз алып барылды, файдалы вәгазь- нәсыйхәтләр сөйләнде.

# Көтеп алынган кунак!

**(Дәвамы. Башы 1нче биттә).**

Ураза сүзе гарәп телендә саум. Бу сүзнең телдәге мәгънәсе – нәрсәдән дә булса тыелу. Ә шәригаттәге мәгънәсе – таң беленгәннән алып кояш батканчыга кадәр ризыктан, эчемлектән, җенси якынлыктан тыелып тору дигәнне аңлата.

Ураза тоткан кеше көне буе гыйбадәт хәлендәдер. Ураза тоту – ач вә сусыз калу түгел. Пәйгамбәребез: "Ялгыз аш–казаныгызга гына ураза тоттырмагыз.

Барча әгъзаларыгызга ураза тоттырыгыз", - ди. Димәк ураза тоткан кеше, үзен аш белән судан тыйган кебек, ямьсез сүзләрдән, ялганнан, гайбәттән, яла ягудан һәм сүз йөртүдән дә, барча бозыклыкларыннан арынырга тиеш. Мөхәммәд(с.г.в) сүзләрен хәтеребездә тоту тиешле: "Әгәр сезнең берәрегез ураза тотса, ул сүгенмәскә һәм кычкырмаска тиеш. Ураза тотучыны тиргиләр яки һөҗүм итәләр икән, ул: "Мин уразада! Мин уразада!" – дип әйтергә кирәк".

Рамазан аенда бигрәктә без үзебезне тәрбияләргә, чыныктырырга тиешбез. Әгәрдә кемдә-кем ризыктан, судан, җенси якынлыктан тыелып та әшәке сүзләр сөйләсә, бозык эшләр эшләсә бу бәндәнең уразасы кабул ителүендә шик бар. Пәйгамбәребез(с.г.в) әйтә: "Кем бозыклык эшләүдән туктамый, Аллаһыга аның ачыгуы кирәкми".(Бухари риваяте) Ураза тоткан кеше күзен, колагын, кулын һәм аягын начар, хәрам эшләрдән саклар. Сәүдә эшендә гаделлек булыр. Ярлыларга ярдәм итәр. Олыларга хөрмәт, кечкенәләргә дә шәфкать һәм мәрхәмәт күрсәтер.

Ураза зур һәм дәрәҗәле бер гыйбадәттер. Аны үтәгән бәндәләргә Аллаһ Тәгаләнең чиксез әҗер-саваплары бар. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: "Кем Аллаһка ышанып һәм савабын Аллаһтан көтеп, ураза тотса, ул кешенең эшләгән гөнаһлары гафу ителер", - дип әйткән.

ПәйгамбәребезМөхәммәд(с.г.в) әйткән: "Ураза тотучының ике шатлыгы бар: берсе авыз ачканда, икенчесе үзенең Раббысы белән очрашканда." Уразаның савабы чиксез. Пәйгамбәребез: "Рамазан ае бик мөбәрак бер айдыр. Бу айның башы – рәхмәт, уртасы – мәгъфирәт, ахыры җәһәннәмнән котылудыр" – ди. Күргәнебезчә, бу ай башка айларга караганда күпкә бәрәкәтлерәк. Шуңа күрә бу айда без мөселманнар мөмкин кадәр Раббыбызга якынаю өчен барлык хәерле гамәлләрне кылырга тырышабыз. Бер сәбәпсез ураза тотмау исә гаеп эштер. Һәм янындагы ураза тотучыга да, һәм җәмгыятькә дә, һәм Раббыбызга карата гаеп. Бигрәк тә, ураза вакытында ураза тотучылар алдында ашап-эчеп йөрү бердә килешеп бетми. Хәлбуки мөселман уразасын хөрмәт күрсәткән мәҗүси турында мисаллар да юк түгел.

Шулай Рамазан кирәргә бер көн кала мәҗүси үз өенең ишегалдында икмәк ашап утырган баласына болай ди: «Улым, иртәгедән башлап икмәкне тышта түгел, ә өйдә ашарсың. Без мөселманнарга ихтирамлы булырга тиешбез. Алар бер ай буенча, Тәңреләрне итагать итеп, ураза тотачаклар!» Шуңа күрә үзебез төрле сәбәпләр аркасында ураза тотмасак та изге айны һәм ураза тотучы мөселманнарны хөрмәтләсәк иде.

Аллаһ Раббыбыз кешеләрне, рух һәм тән берлеге булларак, җир йөзендә яратты. Шуңа күрә тәнне дә, рухыбызны да тәрбияләү безнең бурычыбыз. Тәнне мунча керер чистартабыз. Рухны бит су кертеп яки мунчага кертеп пакълап булмый. Без рухыбызны ураза тотып тәрбиялибез дә инде. Кеше хайваннан камил гакыл белән аерыла. Белгәнебезчә хайваннын тамагы ачса, ул әйберне вата җимерә ризыкка омтыла, әммә без кешеләр буларак, үзебездә ихтияр көче таба алабыз. Үзебезнең тән генә түгел, рух та иканнегебезне искә төшерәбез, шулай итеп рухыбызны зурлыйбыз. Кайберәүләр: "Мин ашамыйча берничек тә түзә алмыйм", - ди. Шулай булгач без хайваннан нәрсәбез белән аерылабыз соң?

Әйткәнебезчә, шик юк уразаның матди һәм мәгънәви бик күп файдалары бар, әммә шуны аңлау тиешле: ураза ялгыз саулык өчен әмер ителгән, фарыз кылынган бер гыйбадәт түгел. Кешенең, Аллаһка якынаюы өчен, Аллаһ Тәгалә тарафыннан барлык милләтләргә фарыз кылынган зур бер гыйбадәттер. Шуны онытмаска кирәк: Без уразаны файдалары өчен түгел, Аллаһ кушканга күрә тотабыз.

Газиз мөселман кардәшләр! Менә инде шәгъбан ае да тәмамланып килә. Тиздән без мөэминнәрнең түземсезлек белән көткән айлары Рамазан ае да җитәчәк. Без Рамазан аен бер кунагыбызны каршылаган кебек каршыласак иде. Без берәр кунагыбызны каршылыйсы булса, аңа алдан әзерләнә башлыйбыз, йортыбызда тәртип ясыйбыз, җыештырабыз.Шуның шикелле Рамазан аена да алдан әзерләнергә тиешлебез.

Әлбәттә, ураза тоту көннәре озыная, әммә моның белән һичшиксез аның әҗере дә арта. Аллага шөкер, бернигә дә карамый елдан-ел ураза тотучыларның саны арта. Яшьләр, урта буын кешеләренең сафлары кубәя. Аллаһы Тәгалә әйтте: "Ураза тоту белән шаят ки сез Аллаһыга якынаерсыз, куңелләрегез нечкәрер, калебләрегез тетрәр, тәкъва бәндәләрдән булырсыз".

Гыйбрәтле ки, элек әби-бабаларыбыз басуларда, кырларда, ындыр табакларында эшләгәннәр, шул ук вакытта уразаларын да калдырмаганнар. Безнең яшәеш күпкә җиңелерәк: табында ни теләсәң шул бар, алдынгы техник чаралары кулланып яшибез. Шуны да онытмаска кирәк, җәннәт тә бит бик кыйммәтле, бәхале-тырышмыйча гына, берникадәр мәшәкатләрне күрмичә генә аңа лаек булып булмый.

Рамазан шәриф аенда Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Аллаһ тарафыннан җибәрелгән Җәбраил фәрештәдән Коръән кәрим дәресләрен ала иде. Шуңа күрә бу ай һәрбер мөселман өчен дәрес ае да булып тора.

Бу айда без факыйрьләрнең, ачларның хәлләрен аңлау дәресен үтәбез. Аларга карата күнелләребез йомшара. Гомумән, жир шарында бар халыкның биштән бере факыйрьлек хәлендә яшәгән вакытта, мөселман кешесенең күнеле тыныч булырмы?

Аллаһы Тагалә Коръәндә әйтте:

"Исраф кылмагыз, Аллаһы исраф кылучыларны яратмый".

Галимнәр санап чыгардылар, әгәр дә һәр кеше чүпкә ташлаган ипи валчыкларын гына җыеп барса да, җир йөзендә бер ач та булмас иде.

Бу айда без сабырлык дәресләрен дә алабыз. Күпләребез көн буе төрле гөнаһлар кылмыйча тузәргә өйрәнә, берәүләребез үзләрен гайбәттән тыеп тору дәрәҗәсенә ирешә. Бу зур дәрес түгелме? Һәрнәрсәнең ачкычы булган кебек, жиңүнең дә ачкычы - сабырлык.

Без үзебезнең нәфесебезне жиңәргә тырышабыз. Ә нәфесне фәкать сабырлык белән генә жиңеп була. Аллаһы Тәгалә бу айда хәттә безне хәләл җефетләребездән дә арындырып торып, нәфесебезне кулга алырга өйрәтә.

Әйе, бу айда без бихисап зур дәресләр алабыз. Эмма һәркайсыбыз да дәресебезне гөмеребез буе утәргә тырышсак иде. Чөнки калган 11 ай да Аллаһныкы. Ул айларда да гөнаһ кылырга рөхсәт юк. Ураза тоту Рамазан белән генә чикләнми, безнең башка айларда да күп нәфел уразаларыбыз бар. Шәүвәл аенда 6 көн, һәр айның уртасында 3 көн, дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә һәм гашура уразалары, калган айларда да Коръән Кәрим уку, һәр ай саен бер хәтем кылу расулебезнең сөннәтеннәндер. Калган айларда да фәкыйрьләрнең ризыкка мохтаж булуларын онытмасак иде.

Раббыбыз, тормышларыбызның һәр көнен Рамазан шәриф аендагы кебек бәхетле, чиста һәм ихласлы, ә төннәребезне Кадер кичләре кебек зекер һәм истигъфарлы итеп уткәрергә насыйп әйләсә иде.

Раббыбыз барча галәмгә муллык вә сәгадәт насыйп әйләсен!

........................................

**ГАБДРАХМАН ХӘЗРӘТ ХӘБИБУЛЛИН.**

# Онытылмаслык хатирәләр




Җәйге каникул вакытында мин Мамадыш мәдрәсәсендә лагерьда булдым. Монда көннәр бик күңелле үтте. Көн дә кызыклы-кызыклы уеннар оештырылды. Сабантуйдагы кебек уенчыклар кисеп алумы, авыз белән су ташып чынаякны тутырумы- барысы да, барысы да булды. Чаллы шәһәренә сәяхәт иттек. Анда төрле аттракционнарда катнаштык, мәчетләрне зыярат кылдык. Табигать кочагында пылау пешерергә, су коенырга да житештек. Һәр көн дини дәресләр дә керде. Биредә үземә бик күп дуслар таптым. Лагерь беткәч тә дусларымны онытмам, алар белән яхшы мөгамәләдә булырмын. Тәрбиячеләргә дә зур рәхмәт. Алар безне үз балаларын яраткан кебек яраттылар. Миңа бу лагерьда бик ошады. Ислам дине белән тагын да ныграк танышырга этәргеч булды. **(Тухбатова Таңсылу, Югары Ушмы).**

“Ихлас” җәйләвендә көннәрнең ничек үткәнен сизми дә калдым. Лагерьның тагын 3 нче сменасы булса, бер дә уйламый тагын калыр идем. Биредә без бик кызыклы уеннар уйнадык, күп белем алдык... Кызыклы –кызыклы мизгелләрнең шаһитләре булдык. Барысын да сөйләп бетереп тә булмый. Шунысы шатландыра: балалар дин белән кызыксына башладылар. Күбесе намаз укырга өйрәнде. Зур рәхмәт безгә белем биргән, безне тәрбияләгән мөгаллимнәргә һәм тәрбиячеләргә. Аларга Аллаһы Тәгалә сабырлык, гаилә бәхете насыйп итсен. **(Пирова Сафармах, Түбән Ушмы).**

Мин быел беренче тапкыр мәдрәсәдә лагерьда катнаштым. Мәдрәсәдә үткән көннәр иң күңелле, рәхәт көннәр иде. Көн саен кызыклы уеннар оештырылды, походларга йөрдек, су коенырга төштек. Мин мәдрәсәдә бик күп дуслар белән таныштым. Файдалы үгет-нәсыйхәтләр, вәгазьләр ишеттем. Шуңа күрә монда килергә мин бүтәннәргә дә тәкъдим итәм. Чөнки биредә күңелле ял да итәсең, гыйлем дә аласың һәм әйбәт дуслар белән дә танышасың. **(Салихова Рамилә, Түбән Кама).**



## Сорау илә җавап

**Хәләл ризыкка нинди таләпләр куела?**

Мин үземнең аркадашым белән зур булмаган хайван чалу һәм ит эшкәртү пункты ачмакчы булам. Хәзерге вакытта планлаштыру һәм проектны раслау эшләре алып барыла. Баштан ук һәммәсен дә дөрес итеп башкарасы килә. Без инде голландлар, французлар тарафыннан тәкъдим ителгән электр белән үтерү һәм кыру машиналарын сүндердек. Әмма «хәләл»нең мәгънәсе төрлечә... Казах картлары аны бер төрле аңлата, муллалар-башкача, сертификат таләпләре-өченче төрле. Киңәш бирсәгезче. Хәләл ризыкка нинди таләпләр куела? Ерик, Казахстан

Таләпләргә килгәндә, сезгә хәләл ризык җитештерү белән шөгыльләнүче оешмаларның махсус әдәбиятын һәм документларын өйрәнергә кирәк. Дөрес, аермалар булырга мөмкин. Аларда төрле аңлатмалар да булуы ихтимал. Шуларны өйрәнеп, сез үзегезгә иң кулай вариантны сайлап алырга тиешсез. Биредә иң мөһиме- Раббыбызның исемен искә алып, хайван муенындагы төп артерияләрне кисү. Монда Аллаһ рөхсәт биргән нәрсәләр -хәләл, тыйганнары хәрам дигән мәсләктән чыгып эш итү мәслихәт. Ә тыелган ризыкларга -үләксә ите, кан, дуңгыз ите, Аллаһ исеме белән чалынмаган терлек, буып яисә башка хайван тарафыннан үтерелгән, югары вольтлы электр тогы белән һәлак ителгән, бәрелеп һәм егылып үлгән хайван ите керә. Ерткыч җәнлекләрне (бүре, юлбарыс, арыслан һәм башкалар) һәм ерткыч кошларны (лачын, карчыга, бөркет һ. б.), эт, ишәк һәм качыр итләрен куллану шулай ук тыела. Мөселманча чалынган хайванның гениталиеләрен, эчке секреция бизләрен, үт һәм бәвел куыгын ризык итеп кулланырга ярамый.

Мөселманнарга ите ризык буларак тәкъдим ителгән терлекне төрле дин һәм милләт вәкилләре дә чалырга мөмкин. Шунысы бар: мөселман булмаган кеше дә хайванның муен артерияләрен кискәндә «Бисмилләһ, Аллаһу әкбәр» сүзләрен әйтергә тиеш.

**Мин-татар кызы. Динем-ислам. Әнисе -татар, әтисе рус булган егеткә кияүгә чыгарга җыенам. Аңа -23 яшь, чукындырылмаган, сайлап алу хокукы биргәннәр. Ул православие ягына тартылмакчы була. Мин үзем дә, әти-әниләрем дә никах укытырга телибез, ләкин аның әтисе моңа каршы . Ул үзенең улын да никахка каршы котырта, моның аларның йолаларына һәм мәсләгенә туры килмәгәнлеге белән аңлата. Мин бөтен гомерем буена никах укыту турында хыялландым һәм аңа бу хакта күп тапкырлар әйттем. Бу мәсьәләне ничек хәл итәргә, аңа нинди дәлилләр китерергә? Ул хәтта чукыну белән дә куркыта. Атасы аның өчен зур абруйга ия. Алия**

Аңа кияүгә чыксагыз, үз тормышыгызны җимерәчәксез. Аннары инде кире кайтарып алырга соң булачак. Хәзергә сез моны бәлки аңлап та бетермисездер, әмма бернишә ай бергәләп яшәгәннән соң, моны бөтен барлыгыгыз белән тоячаксыз. Сезгә барлык ихтыяр көчегезне туплап, бу егетне онытырга кирәк. Шулай эшләгәндә зирәк акыллы һәм көчле кешегә әйләнерсез. Җирдә берничә миллиард яшүсмер һәм ир заты бар. Димәк, фикерләрегезне уртаклашучының табылуына шикләнмәскә мөмкинлек зур.

**Мин ирекле көрәш белән шөгыльләнәм. Без тәнгә сыланып торган трико киябез. Безнең тезләребез ачык, бу, белеүмчә, гөнаһ. Мин чамадан тыш күнегүләр ясарга яратам. Организмны шул тиклем көчләргә ярыймы? Ярышларда катнашу дөресме?Мансур.**

Дөрес, әмма дә иркенрәк трико булса, яхшырак инде. Мәсәлән, бер үлчәмгә артыграк трико киегез. Икенче сорауга — катгый рәвештә тиешле дип әйтмәс идем. Организмга ни дәрәҗәдә киеренкелек бирү турында үз тренерыгыз яки табиб белән сөйләшегез. Ярышларда катнашу рөхсәт.

## Кайгыларын уртаклашабыз

«Булгария» су көймәсендә булган фаҗига җәмгыятьне тетрәтте. Һәр кеше үз йөрәге аша уздырып хәсрәтле көннәр уздыра. Мамадыш мәдрәсәсе коллективы һәм “Нәсыйхәт” газетасы редакциясе «Булгария» теплоходы фаҗигасе корбаннары гаиләләренең тирән кайгысын уртаклаша.

Аллаһы Тәгаләдән әлеге фаҗигадә һәлак булучыларның туганнары һәм якыннарына рухи көч һәм сабырлык бирүен сорыйбыз. Раббыбыз һәлак булганнарның гөнаһларын ярлыкасын, сират күперләрен үткәндә, рәхим-шәфкатеннән ташламасын иде.

Бу һәлакәт безгә гыйбрәт бирә, Аллаһка күбрәк гыйбадәт кылырга этәрә. Чөнки теләсә кайсы вакытта вафат булуыбыз ихтимал. Кайда гына булсак та, Аллаһ Тәгалә җибәргән үлем барыбер тотар, шуңа күрә үлемгә кадәр изге гамәлләр кылып, гөнаһлардан тыелып, һәрвакыт әзер булырга кирәк.

## Намаз вакытлары

| Көн саны | Фәҗер Иртәнге намаз | Кояш чыга | Зухр Өйлә намазы | Аср Икенде намазы | Мәгъриб Ахшам намазы | Гыйшә Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 3.10 | 4.39 | 12.41 | 18.08 | 20.43 | 22.13 |
| 2 | 3.11 | 4.41 | 12.41 | 18.07 | 20.41 | 22.11 |
| 3 | 3.13 | 4.43 | 12.41 | 18.06 | 20.39 | 22.09 |
| 4 | 3.15 | 4.45 | 12.41 | 18.05 | 20.37 | 22.07 |
| **5** | **3.17** | **4.47** | **12.41** | **18.04** | **20.35** | **22.05** |
| 6 | 3.19 | 4.49 | 12.41 | 18.03 | 20.33 | 22.03 |
| 7 | 3.21 | 4.51 | 12.41 | 18.01 | 20.31 | 22.01 |
| 8 | 3.22 | 4.52 | 12.41 | 18.00 | 20.29 | 21.59 |
| 9 | 3.24 | 4.54 | 12.40 | 17.57 | 20.26 | 21.56 |
| 10 | 3.26 | 4.56 | 12.40 | 18.54 | 20.24 | 21.54 |
| 11 | 3.28 | 4.58 | 12.40 | 17.53 | 20.22 | 21.52 |
| **12** | **3.30** | **5.00** | **12.40** | **17.50** | **20.20** | **21.50** |
| 13 | 3.32 | 5.02 | 12.40 | 17.49 | 20.17 | 21.47 |
| 14 | 3.34 | 5.04 | 12.40 | 17.47 | 20.15 | 21.45 |
| 15 | 3.36 | 5.06 | 12.40 | 17.46 | 20.13 | 21.43 |
| 16 | 3.38 | 5.08 | 12,39 | 17.45 | 20.10 | 21.40 |
| 17 | 3.40 | 5.10 | 12.39 | 17.44 | 20.08 | 21.38 |
| 18 | 3.42 | 5.12 | 12,39 | 17.44 | 20.06 | 21.36 |
| **19** | **3.44** | **5.14** | **12.39** | **17.42** | **20.03** | **21.33** |
| 20 | 3.46 | 5.16 | 12.39 | 17.40 | 20.01 | 21.31 |
| 21 | 3.48 | 5.18 | 12.38 | 17.37 | 19.59 | 21.29 |
| 22 | 3.50 | 5.20 | 12.38 | 17.35 | 19.56 | 21.26 |
| 23 | 3.52 | 5.22 | 12.38 | 17.32 | 19.54 | 21.24 |
| 24 | 3.53 | 5.23 | 12.38 | 17.31 | 19.51 | 21.21 |
| 25 | 3.56 | 5.26 | 12.37 | 17.30 | 19.49 | 21.19 |
| **26** | **3.58** | **5.28** | **12.37** | **17.28** | **19.46** | **21.16** |
| 27 | 3.59 | 5.29 | 12.37 | 17.26 | 19.44 | 21.14 |
| 28 | 4.01 | 5.31 | 12.36 | 17.24 | 19.42 | 21.12 |
| 29 | 4.03 | 5.33 | 12.36 | 17.22 | 19.39 | 21.09 |
| 30 | 4.05 | 5.35 | 12.36 | 17.21 | 19.37 | 21.07 |
| 31 | 4.07 | 5.37 | 12.36 | 17.19 | 19.34 | 21.04 |

# Ни чәчсәң, шуны урырсың

Беркөн бер авыл карты мөфти-казый әфәндегә килеп улына шикаять белдерә:

— Мөхтәрәм казыем, кичә мине улым кырда кыйнады, үгезләр куа торган чыбыркысы белән сукты. Җаным бик әрнеде, бик еладым.. Мин баламны шуның өчен үстердеммени? Бу картлык хәлемдә мин хәзер ни эшлим инде? Бүген менә сиңа килдем, бер юл күрсәт миңа, бер акыл бир. Мин хәзер ни кылырга да белмим, хуҗам, ялварам, сиңа, миңа ярдәмче бул.

Казый әфәнде:

— Сөбхәналлаһ! Ничек инде бала атасына кул күтәреп сугар! Әллә син улыңа дин өйрәтмәдеңме? Ата-ана хакының
изгелеген улыңа аңлатмадыңмы? Кечкенәдән әхлак, тәрбия
үрнәкләре бирмәдеңме?

Карт:

- Хөрмәтле хуҗам! Авыл тормышын беләсең бит, сез әйткәннәрне өйрәтмәдем шул. Авыл җирендә эш күп, кыенлыклар-мәшәкатьләр күп, хайваннар карыйсы, иген үстерәсе, утын әзерлисе... Боларның берсен дә эшләмичә булмый.

Казый күзе яшьле картка:

- Алай булгач инде, бабакай, син улыңны гаепләмә. Ул
сине җир сөрә торган үгезләре белән бер саный. Чөнки улың
өчен синең белән үгезләр арасында бернинди аерма да юк.

Улыңа ата кадерен өйрәтмәгәнсең. Ул үгезләргә сугам дип,
сиңа суккан. “Юкса, бала атасына кул күтәрмәс иде,”... - дип,
картның улына карата әтилек вазыйфаларын үтәмәгәнлеген аңлатты.

............................

**ЮСЫФ ТАУСЛЫ**

## Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

**МАМАДЫШ МӘДРӘСӘСЕ КИЛӘСЕ 2011 - 2012 УКУ ЕЛЫНА** шәкертләр туплый. Мәдрәсәгә тугызынчы сыйныфны тәмамлаган ир-егетләр кабул ителә. Дәресләр кичке уку рәвешендә алып барылачак. Документларны кабул итү 1 июльдән башлана. Шул исәптән Мамадыш мәдрәсәсе яше чикләнмәгән ир-ат һәм хатын-кызларны кичке уку бүлекләренә укырга чакырып кала. Беренче курска керүчеләрдән түбәндәге документлар таләп ителә:

1.Гариза (мәдрәсә бланкасына тутырыла)
2.3 х 4 зурлыгындагы 4 данә аклы - караны фоторәсем;
3. Белем таныклыгының копиясе;
4. Паспорт копиясе;

1 курска кабул ителгән ир-егетләрнең укулары 2 сентябрьдә сәг. 16:00 дә  ә ир-ат һәм хатын-кызларның укулары 3 октябрьдә сәг. 17:00 дә башланачак. Мәдрәсәбезгә рәхим итегез!

**ҮЗЕБЕЗНЕ РУХИ РИЗЫКТАН МӘХРҮМ ИТМИК!**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 100 данә.**